ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.04.2021 Олы Кайбыч ав. № 147

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 12 сентябрендәге 524 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 5 ноябрендәге 999 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 12 сентябрендәге 524 номерлы (2014 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы, 2014 елның 7 февралендәге 67 номерлы, 2016 елның 15 апрелендәге 161 номерлы, 2017 елның 15 февралендәге 55 номерлы, 2018 елның 26 гыйнварындагы 26 номерлы, 2019 елның 20 декабрендәге 560 номерлы, 2020 елның 7 апрелендәге 182 номерлы, 2020 елның 29 декабрендәге 569 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.2.1 пункт өстәргә:

«1.2.1. Җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә белем бирү оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган кереме аны билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

2.1 пунктындагы 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«компенсация билгеләү турында гариза бирелгән ай алдыннан алты календарь

айга кадәрге 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре турында документлар;»;

2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның ризалыгы булганда компенсация билгеләү компенсация билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге 12 календарь айда гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәре турында белешмәләр нигезендә башкарыла;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 01 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җиитәкче А.Н.Макаров